**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

пр. Ленина, дом 17, с. Актаныш, 423740

Ленин пр.,17йорт,Актаныш ав.,423740

Тел.(85552) 3-44-22, факс (85552)3-44-14, E-mail:aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　КАРАР

___________　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　№ ___________

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Качкын төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесен һәм «Качкын балалар бакчасы» структур бүлекчәсен бетерү турында**

Россия Федерациясе Граждан кодексының 61-64 статьялары, «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 124-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктына таянып, 2022 елның 26 маеннан Актаныш муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмасын үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү комиссиясенең 27 нче номерлы бәяләмәсе, 2022 елның 20 апреленнән Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Качкын авылы гражданнар җыенының беркетмәсе нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «Качкын төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесен һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Качкын балалар бакчасы» структур бүлекчәсен 2022 елның 27 маеннан бетерергә.

2. Бетерелә торган мәгариф учреждениесе документларын саклау өчен җаваплы итеп «Пучы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесен билгеләргә.

3. «Качкын төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры Р.С.Мирзаяновага:

- хезмәт законнары нигезендә бетерелә торган мәгариф учреждениесе штатларын кыскарту процедурасын үткәрүне тәэмин итәргә;
- «Качкын төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесен һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Качкын балалар бакчасы» структур бүлекчәсен закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә бетерергә.

4. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru.бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Л.Ф.Нурлыевага йөкләргә.

Җитәкче　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　Р.А.Ильясов